**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 10 март № 141

г. Казань

2015 – 2019 елларга Татарстан Республикасында муниципаль һәм төбәк телевидение тапшыруын саклап калу һәм үстерү концепциясен раслау турында

Санлы технологияләргә күчү шартларында Татарстан Республикасы территориясендә төбәк телевидение тапшыруын үстерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2015 – 2019 елларга Татарстан Республикасында муниципаль һәм төбәк телевидение тапшыруын саклап калу һәм үстерү концепциясен (алга таба – Концепция) расларга.

2. Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына, кызыксынучы министрлыклар һәм ведомстволар белән берлектә, Концепцияне тормышка ашыру чаралары планын эшләргә һәм 2015 елның 1 июненә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертергә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 10 март, 141 нче
карары белән расланды

2015 – 2019 елларга Татарстан Республикасында муниципаль һәм төбәк телевидение тапшыруын саклап калу һәм үстерү концепциясе

**Билгеләр һәм билгеләмәләр**

Бу Концепциядә түбәндәге билгеләр һәм билгеләмәләр файдаланыла:

IP-TV – IP беркетмәсе буенча мәгълүматлар тапшыру челтәрләрендә санлы телевидение технологиясе;

WiMax – җайланмаларның киң спектры өчен зур араларда универсаль үткәргечсез элемтә белән тәэмин итү максатыннан чыгып эшләнгән телекоммуникация технологиясе;

3 нче буын үткәргечсез элемтә (3G) - «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре күрсәтә торган хезмәтләрдән югары тизлек белән мобиль файдалану мөмкинлеген дә, мәгълүматлар тапшыру каналын булдыручы радиоэлемтә технологиясен дә берләштерә торган хезмәтләр күрсәтү җыелмасы;

4 нче буын үткәргечсез элемтә (4G) – мәгълүматларны югары тизлектә тапшыру һәм югары сыйфатлы тавыш элемтәсе белән башкалардан аерып торучы 4 нче буын мобиль элемтә технологиясе. 4 нче буынга тизлеге секундына 100Мбиттан артып киткән мәгълүматлар тапшыруны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә торган перспективалы технологияләрне кертү гадәткә кергән;

тапшыручы – телевидение тапшыруына, радио тапшыруына лицензия нигезендә телеканал яки радиоканал булдыруны һәм аны билгеләнгән тәртиптә таратуны гамәлгә ашыручы Россия юридик заты;

кабельле телевидение (КТВ) – телесигнал кулланучыга сузылган кабель аша тапшырылучы югары ешлыклы сигналлар ярдәмендә тарала торган телевидение тапшыруы моделе;

мультиплекс – телерадиотрансляцияләре бер радиоешлык каналыннан файдаланып гамәлгә ашырыла торган теле- һәм радиоканаллар пакеты;

муниципаль телеканал – бер муниципаль берәмлек территориясе чикләрендә телевидение каналы тапшыруына лицензиясе булган телевидение тапшыруы оешмасы;

элемтә операторы – элемтә хезмәтләре күрсәтү өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыруга лицензия нигезендә элемтә хезмәтләре күрсәтүче юридик зат яки шәхси эшмәкәр;

төбәк телеканалы – бер төбәк территориясе чикләрендә телевидение каналы тапшыруына лицензиясе булган телевидение тапшыруы оешмасы.

1. Гомуми нигезләмәләр

Бу Концепция 2015 – 2019 елларга Татарстан Республикасында муниципаль һәм төбәк телевидение тапшыруларын үстерүнең төп юнәлешләрен билгели.

Технологияләр интенсив үскән чорда телевидение һәм радио тапшыруы үз позицияләрен бирми һәм элеккечә иң әһәмиятле массакүләм мәгълүмат чараларының берсе булып кала. Ләкин телерадиоканаллар аналоглы форматта таралу бүгенге көндә күп энергия, материал һәм хезмәт сорый, ә кабат җитештерү принцибы буенча тапшыруның аналоглы челтәрләрен модернизацияләү (бигрәк тә тапшыруның яңа каналларын оештыру өчен) буш радиоешлык ресурсының чикле булуын исәпкә алганда перспективасыз булып тора.

Татарстан Республикасы өчен муниципаль һәм төбәк тапшыруын саклап калу һәм үстерү мәсьәләсе аеруча мөһим, ул Татарстан Республикасының мәдәни традицияләрен саклап калу өчен шартлар тудыруга ярдәм итә, рухи кыйммәтләр формалаштыруга булышлык күрсәтә һәм республика мәдәниятенең аерылгысыз өлеше булып тора.

Бүгенге көндә республикада түбәндәге спутник операторлары тапшыру гамәлгә ашыра: НТВ+, Триколор ТВ, Радуга ТВ, Континент ТВ, Телекарта ТВ. Аларның абонентлары, кагыйдә буларак, – аналоглы эфир телевидениесе сигналының сыйфаты түбән һәм кабул ителә торган программалар составы канәгатьләнерлек булмаган шәхси йортларда яшәүче хәлле авыл һәм шәһәр халкы. Халыкның спутник телевидениесе тапшырулары белән тәэмин ителеше йорт хуҗалыкларының 10 процентын тәшкил итә һәм сигналны теләсә кайсы географик ноктада кабул итәргә мөмкинлек бирә, шуның белән бергә, телеканаллар тәкъдим итә торган пакетларда муниципаль һәм төбәк контенты тулысынча юк диярлек.

Абонентлар өчен «Россия телевидение һәм радио тапшыруы челтәре» федераль дәүләт унитар предприятиесенең эфир телерадиотапшыру челтәре арзанрак вариант булып тора. Хәзерге вакытта ул күрсәтә торган хезмәтләрдән шәхси йортлары булган аз керемле шәһәр һәм авыл халкы файдалана. Татарстан Республикасы халкының «Беренче канал», «Россия 1», «Татарстан – Яңа гасыр» телеканалларының аналоглы тапшыруы белән тәэмин ителеше – йорт хуҗалыкларының 99,8 процентын, 1 нче мультиплекс санлы эфир телетапшыруы белән тәэмин ителеше – йорт хуҗалыкларының 86 процентын, 2 нче мультиплекс тапшыруы белән тәэмин ителеше йорт хуҗалыкларының 72 процентын тәшкил итә.

Россия Федерациясенең Элемтә һәм массакүләм коммункацияләр министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте ярдәмендә шәхси оператор – җаваплылыгы чикләнгән «Радиотелеком» җәмгыяте тарафыннан Казан шәһәрендә һәм республиканың 6 торак пунктында (Югары Ослан авылы, Әлмәт шәһәре, Буа шәһәре, Тәтеш шәһәре, шәһәр тибындагы Апас поселогы, Шәмәрдән авылы) йорт хуҗалыкларының 40,5 процентын эфир тапшыруы белән тәэмин итәргә мөмкинлек биргән санлы эфир тапшыруы челтәре төзелде.

Хәзерге вакытта республика территориясендә кабельле челтәрләр һәм IP-TV челтәрләре буенча телерадиотапшыру хезмәтләрен түбәндәге элемтә операторлары: республикадагы түләүле телевидение базарының шактый зур өлешенә ия булган «Таттелеком» ачык акционерлар җәмгыяте, «ЭР-Телеком Холдинг» ябык акционерлар җәмгыяте, «Мобильные ТелеСистемы» ачык акционерлар җәмгыяте, «Ростелеком» ачык акционерлар җәмгыяте, «Вымпелком» ачык акционерлар җәмгыяте, «Казгорсеть» ябык акционерлар җәмгыяте күрсәтә. КТВ күрсәтә торган хезмәтләрдән шәһәр һәм авыл торак пунктларының күпфатирлы йортларында яшәүчеләр файдалана. Хезмәт күрсәтүгә тарту йорт хуҗалыкларының 45 процентын

тәшкил итә. Үз чиратында республика халкын мәгълүматлар тапшыру челтәрләрендә санлы телевидение технологиясенә (IP-TV) тарту йорт хуҗалыкларының 6 процентын тәшкил итә.

Татарстан Республикасында 3 нче һәм 4 нче буын үткәргечсез элемтә операторлары челтәре аша телевидение тапшыруларын карау популяр була бара. Кагыйдә буларак, мондый сервислар мобиль җайланмалардан (планшетлардан, смартфоннардан) файдаланучыларга; челтәр медиаплеерларына; миниатюр абонент приставкаларына (Android Sticker), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре күрсәтә торган хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеге булган телевизорларга (SMART TV) һәм уен консольләренә (Sony PS, Microsoft Xbox) йөз тота.

2. Стратегик максатлар

Телевидение тапшыруын оештыруның стратегик максаты булып түбәндәгеләрне тәэмин итү тора:

Татарстан Республикасының муниципаль һәм төбәк телеканаллары тапшыруын;

Татарстан Республикасы йорт хуҗалыкларының кимендә 95 проценты өчен телевидение тапшыруы хезмәтләре күрсәтүдән файдалана алу мөмкинлеген (аналоглы эфир тапшыруын исәпкә алымыйча);

телевидение тапшыруы хезмәтләрен сыйфатлы итеп күрсәтүне;

халыкның кабул ителә торган контентны сайлап алу мөмкинлеген;

халыкның телевидение сигналын кабул итү ысулын сайлау алу мөмкинлеген.

3. Стратегик максатларны тормышка ашыруның төп юнәлешләре

3.1. Татарстан Республикасының муниципаль һәм төбәк телеканаллары тапшыруын тәэмин итү.

Татарстан Республикасы территориясендә булдырыла торган мәгълүмат киңлегенә республика халкы керә алу мөмкинлеген тәэмин итүнең әһәмиятен исәпкә алып, билгеләнгән тәртиптә төбәк һәм муниципаль телеканалларны 3 нче һәм 4 нче мультиплексларга тоташтыру эшен оештырырга кирәк.

3.2. Телевидение тапшыруы хезмәтләре күрсәтүдән һәркем файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү.

3.2.1. Эшне оештыру өлешендә түбәндәгеләрне башкарырга кирәк:

тоткарлый торган өстәмә факторлар килеп чыгуны булдырмый калу максатларында, телевидение тапшыруы челтәренә абонент җиһазлары белән дә, оператор бирә торган җиһазлар белән дә тоташтыру ысулларын билгеләргә;

җиһазларга карата куела торган телепрограммаларны кабельле һәм эфир тапшыруы челтәрләре буенча кабул итү мөмкинлеген тәэмин итәчәк минималь таләпләрне билгеләргә;

халык керә ала торган барлык мәйданчыкларда телевидение челтәрләренә тоташтыру мәсьәләләре, файдаланып була торган абонент җиһазлары типлары, телеканаллар исемлеге, пакетларның кыйммәте буенча тәкъдим итү һәм белешмә бирү характерында мәгълүмат урнаштырырга;

абонентларга телевидение тапшыруы челтәренә тоташтыру стадиясендә генә түгел, хезмәтләр күрсәтүдән файдаланган вакытта да ярдәм итү регламентын эшләргә.

3.2.2. Хезмәтләр күрсәтү өлешендә түбәндәгеләрне билгеләргә кирәк:

йорт хуҗалыгын оператор челтәренә абонент җиһазларыннан яки оператор бүлеп бирә торган җиһазлардан файдаланып тоташтырганда финанс шартларын;

өстәмә хезмәтләр күрсәтү һәм сервис, шул исәптән абонент җиһазларын башлангыч көйләү кыйммәтен;

һәркем файдалана ала торган мәҗбүри гомумроссия каналларыннан тыш тагын муниципаль һәм төбәк телеканалларын да үз эченә алган телеканаллар пакетына минималь түләү белән халыкның барлык категорияләре өчен файдалана алырлык «Социаль» тибындагы тариф планнарын. Мондый пакетның составында, 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап, муниципаль һәм төбәк телеканалларының гомуми өлеше бу территориядә тапшыра ала торган муниципаль һәм төбәк телеканалларының кимендә 60 проценты булырга тиеш;

санлы тапшыруга күчкәндә республиканың социаль якланмаган халкын һәркем файдалана ала торган мәҗбүри гомумроссия телеканалларыннан файдалануның бертигез шартлары белән тәэмин итү буенча беренче чираттагы чараларны.

3.3. Сыйфатлы телевидение тапшыруын тәэмин итү.

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә керү тизлекләрен арттыру, шулай ук күрсәтелгән челтәргә үткәргечсез керү челтәрләрен (3G, 4G, Wi-Fi һәм Wi-Max) үстерү телевидение контентын аның сыйфатын начарайтмыйча (шул исәптән НД форматында) әлеге челтәр аша трансляцияләү өчен уңай шартлар тудырачак.

Электр-магнит кырлары тәэсирен булдырмау, үткәрү сәләтен җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин итү, элемтә линияләренең ышанычлылыгына ирешү максатларында, республика территориясендә урнашкан барлык төп станцияләргә кадәр киң полосалы кабельле элемтә каналын салырга кирәк.

Телепрограммаларны халыкка җиткерүне оештырганда сыйфатлы контент тәкъдим итү максатларыннан чыгып, тапшыру территориясенең җирле кушымталары белән туры китерүгә ирешеп, республика территориясен зоналарга бүлүне тәэмин итәргә кирәк.

3.4. Кабул ителә торган контентны сайлап алу мөмкинлеген тәэмин итү.

Казан шәһәрендә һәм Татарстан Республикасында тамашачыларның санлы мультиплекслар составына керми һәм санлы тапшыруга лицензияләре булмаган җирле һәм төбәк телеканалларына өстенлек бирүен игътибарга алып, шулай ук 2 нче мультиплекс тапшыруы бүгенге көндә Россиянең халык саны 50 мең кешедән кимрәк булган барлык шәһәрләрендә дә туктатып торылуны һәм, шул рәвешле, 3 нче һәм 4 нче мультиплексларны эшләтеп җибәрү перспективалары ачык булмау, аларга Татарстан Республикасының муниципаль һәм төбәк телеканаллары керү перспективалары да билгеләнмәү сәбәпле, республика халкына телевидение сигналын илтеп җиткерүнең альтернатив ысулларын үстерү мәсьәләсен карарга кирәк.

Кабул ителә торган контентны сайлап алу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасының муниципаль һәм төбәк телеканалларын үстерү өчен уңайлы шартлар тудырырга кирәк, шул исәптән:

кабельле элемтә операторлары телеканаллары пакетларында муниципаль һәм төбәк телеканаллары булу өлешен билгеләргә;

кабельле элемтә операторлары телеканаллары пакетларына муниципаль һәм төбәк телеканаллары керү шартларын билгеләргә;

конкурста муниципаль һәм төбәк телеканаллары катнашу өчен аерым шартлар тудыру, бик үк каты булмаган таләпләр белән квота билгеләү буенча тәкъдимнәр әзерләргә;

телевидение тапшыруы хезмәтләре күрсәтү базарының шактый зур өлешенә ия булган элемтә операторларыннан конкурс нигезендә челтәрләре базасында Татарстан Республикасы йорт хуҗалыкларын телевидение тапшыруы белән мөмкин кадәр күбрәк тәэмин итүгә ирешү буенча эш башкарачак төп элемтә операторларын билгеләргә.

3.5. Телевидение сигналын кабул итү ысулын сайлап алу мөкинлеген тәэмин итү.

Телевидение сигналын трансляцияләүне гамәлгә ашыручы операторлар өчен конкурентлы мохит тәэмин итү максатларыннан чыгып, бер үк вакытта эфир һәм кабельле тапшыруны (шул исәптән IP-TV технологиясе буенча яки элемтә операторларының үткәргечсез челтәрләреннән файдаланып) үстерү өчен шартлар тудырырга кирәк.

3.6. Түләүле телевидение челтәрләрендә муниципаль һәм төбәк телекомпанияләре тапшыруын техник яктан тормышка ашыруны тәэмин итү.

Татарстан Республикасында муниципаль һәм төбәк телекомпанияләренең кабельле телевидение һәм төп элемтә операторларының IP-TV челтәрләрендә тапшыру мөмкинлеген оештыру өчен һәм Татарстан Республикасы йорт хуҗалыкларын телевидение тапшыруы белән мөмкин кадәр күбрәк тәэмин итү эшләрен гамәлгә ашыру максатларында сүс-оптика элемтә линияләрен төзү эшләрен күздә тотарга, тиешле җиһазлар сатып алуны һәм монтажлауны гамәлгә ашырырга, шулай ук сайлап алынган өстенлекле юнәлешләр нигезендә эшләрнең бүтән төрләрен башкарырга кирәк.

4. Концепцияне тормышка ашыру механизмы

Концепцияне тормышка ашыру максатларында аны тормышка ашыру буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга кирәк.

Бу Концепция нигезләмәләренең бер өлешен тормышка ашыру финанс чаралары бүлеп бирүне тәэмин итүгә бәйле рәвештә, Концепцияне тормышка ашыру буенча чаралар планын эшләү барышында аларның чыганакларын карарга кирәк.

5. Стратегик максатларны гамәлгә ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр

2019 елның 1 гыйнварына муниципаль, төбәк һәм федераль каналларның сыйфатлы телевидение тапшыруы белән тәэмин итү, аналоглы эфир тапшыруын исәпкә алмыйча, Татарстан Республикасы территориясендәге йорт хуҗалыкларының кимендә 95 процент тәшкил итәргә тиеш.